# КАРАР

**5 декабрь, 2024 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге Мәчкәрә авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 05 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Мәчкәрә авылының Октябрь, М. Җәлил, Үзәк урамнарында урам-юл челтәрен карап тоту, юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, ташу, җәю, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, торба сатып алу, (эш өчен шартнамә буенча түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру); (Мәчкәрә авылы юлларын кардан чистарту, юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту, шартнамә буенча түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт хакы түләү, проект-смета документлары, шартнамә буенча эш өчен түләү); (Мәчкәрә авылының урам-юл челтәрләренә су үткәрү торбасын урнаштыру, сатып алу, кайтару, урнаштыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру (шартнамә буенча түләү), проект-смета документларын эшләү);

**- һәйкәлләрне рәтләү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне рәтләү, ремонтлау һәм карап тоту,** проект-смета документлары **һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);**

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлаштыру, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин

итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, койма, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка эш төрләре, шартнамә буенча түләү);
**- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма тоту, ремонтлау** (материал, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, зираттагы агачларны кисү, коймасын ремонтлау, территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, (шартнамә буенча түләү), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (Мәчкәрә авылы территориясен төзекләндерү, шартнамә буенча түләү, проект-смета документлары, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 162 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 87 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 87 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Мәчкәрә авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Күкшел авыл җирлеге Мәчкәрә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге баласын тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Мәчкәрә авылының Октябрь, М. Җәлил, Үзәк урамнарында урам-юл челтәрен карап тоту, юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, ташу, җәю, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-
дөрес дип танырга.
смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, торба сатып алу, (эш өчен шартнамә буенча түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
(Мәчкәрә авылы юлларын кардан чистарту, юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту, шартнамә буенча түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт хакы түләү, проект-смета документлары, шартнамә буенча эш өчен түләү);
(Мәчкәрә авылының урам-юл челтәрләренә су үткәрү торбасын урнаштыру, сатып алу,

кайтару, урнаштыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру (шартнамә буенча түләү), проект-смета документларын эшләү);
- **һәйкәлләрне рәтләү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне рәтләү, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);**
- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлаштыру, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, койма, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне карап тоту буенча башка эш төрләре, шартнамә буенча түләү);
- **традицион күмү урыннарын төзекләндерү, койма тоту, ремонтлау** (материал, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, зираттагы агачларны кисү, коймасын ремонтлау, территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, (шартнамә буенча түләү), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (Мәчкәрә авылы территориясен төзекләндерү, шартнамә буенча түләү, проект-смета документлары, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

**кабул ителгән дип исәпләргә.**

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәмидуллин